*Исправления не допускаются!*

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год**
**9 класс**

**Шифр ______** **Итоговой балл ______** **________**подпись предс. жюри

I. Текстны тәрҗемә итегез һәм геройлар җавабы формасында әкиятне дәвам итегез (6-8 җөмлә). – Переведите текст и в форме ответа героев продолжите сказку (6-8 предложений). **(10 баллов)**

Сулейман мудрый

Рассказывают, что когда мудрый царь Сулейман состарился, он стал бояться смерти. И тогда к нему явился повелитель злых духов и сказал:

- О царь! Прими этот волшебный сосуд с живой водой. Выпей ее, и ты обретешь бессмертие.

Но старый царь Сулейман был мудр и потому осторожен. И он приказал, чтобы к нему привели первых трех проходящих мимо его дворца. И вскоре предстал перед царем знатный воин, богатый купец и простой земледелец.

Спросил Сулейман каждого из них:

- Скажи, буду ли я счастлив, выпив живой воды?

**II.** Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. **(25 баллов)**

1. [а] авазына туры килгән билгеләмәне табыгыз. (Определите квалификационные признаки звука [а])

а) алгы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык; ә) арткы рәт, урта күтәрелешле, иренләшмәгән кыска сузык; б) арткы рәт, түбән күтәрелешле, иренләшмәгән озын сузык; в) алгы рәт, югары күтәрелешле, иренләшмәгән сузык.

2. Тартык аваз ике хәреф белән бирелгән сүзне билгеләгез. (Определите слово, где согласный звук передан двумя буквами)

а) игътибар; ә) урындык; б) балык; в) шәһәр.

3. Кайсы сүздә татар теленә хас ирен-ирен [w] авазы ишетелә? (На каком ряду слово, которое произностися с губно-губным согласным w?)

а) вагон; ә) тавык; б) телевизор; в) диван.

4. Кайсы сүздә басым дөрес күрсәтелгән? (Ударение какого слова определено правильно?)

а) язгансың (3 нче иҗектә); ә) урманчы (3 нче иҗектә); б) бармагыз (2 нче иҗектә); в) барлык (2 нче иҗектә).

5. Инфинитив кушымчаларының дөрес язылышын билгеләгез. (Определите, на каком варианте правильно написаны аффиксы инфинитива.)

а) китергә, язырга; ә) китәргә, язарга; б) китәргә, язырга; в) китергә, язарга.

6. Төрки-татар чыгышлы сүзне күрсәтегез.(Определите слово тюрко-татарского происхождения.)

а) гаеп; ә) җир; б) самовар; в) җиһан.

7. Мисалларда сүзләр узара антоним булган вариантларны күрсәтегез.(Определите ряд слов, где представлены антонимы.)

а) хәзер, әзер, гаҗәп, әҗәт; ә) көн, төн, иртә, кич; б) күңел, җан, йөрәк, бәгырь; в) тагы, янәдән, кабат, янә.

8. Түбәндәге җөмләдә нинди лексик берәмлек кулланылган? (Какая лексическая единица употреблена в предложении?)

*- Менә йокы чүлмәге! - дип торды әтисе аптырап (Л.Ихсанова)*

а) диалекталь сүз; ә) һөнәрчелек лексикасына караган сүз; б) күпмәгънәле сүз; в) фразеологик берәмлек.

9. *Күзләр - күңел дәрьясы* җөмләсендә *күңел* сүзенең лексик мәгънәсен күрсәтегез. (В приведенном предложении определите лексическое значение слова *күңел.)*

а) исем сүз төркеменә карый; берлек санда, баш килештә; ә) тамыр сүз; б) күчерелмә мәгънәдә килгән; в) кешенең эчке, рухи дөньясы, аның кичерешләре, хис-тойгылары.

10. Җөмләдә кайсы сүз күчерелмә мәгънәдә кулланылган? (Какое слово в предложении употреблено в переносном значении?)

*Җәйге көн әкренләп кенә сүнде, ниһаять төн булды (Ә.Еники)*

а) җәйге ә) сүнде б) көн в) булды

11. Җөмләдә аерым бирелгән фигыльнең төркемчәсен дөрес билгеләгез. (Определите грамматическую форму глагола, который выделен в предложении)

*Сиңа әнә теге Ташкичүдән **килгән** кунак кызы ошыймы? (М.Мәһдиев)*

а) үткән заман хикәя фигыль; ә) хәл фигыль; б) үткән заман сыйфат фигыль; в) бу сүз фигыль түгел, сыйфат.

12. *-аһ, уф, чү, ай-һай* сүзләре кайсы сүз төркеменә карый? (К какой части речи относятся

приведенные слова?)

а) аваз иялтемнәре; ә) бәйлекләр; б) ымлыклар; в) кисәкчәләр.

13. Җөмләдә аерып бирелгән исемнең килешен дөрес билгеләгез. (Определите падеж выделенного слова.)

*Гаҗәп бит! **Җиңгәчәсенең** сүзендә ник бер сыкрану ишетелсен! (Ә.Еники)*

а) чыгыш килешендә; ә) юнәлеш килешендә; б) иялек килешендә; в) урын-вакыт килешендә.

14. Кайсы рәттә киләчәк заман сыйфат фигыль бар? (На каком ряду представлено причастие будущего времени?)

а) укылган китап; ә) язгач бирәчәк; б) тыңлап эшләр; в) әйтәсе сүз.

15. *Көмештәй, анынча, ефәктәй* рәвешләренең кайсы төркемчәгә керүен күрсәтегез. (Укажите, к какой группе относятся приведенные выше наречия)

а) саф рәвешләр; ә) сәбәп-максат рәвешләре; б) охшату-чагыштыру рәвешләре; в) күләм-чама рәвешләре.

16. Хаталы сүтезмәне табыгыз.(Определите ошибочное словосочетание.)

а) киң мәйдан; б) тирән тау; в) биек манара; г) фәнни хезмәт.

17. Җөмләнең төрен билгеләгез. (Определите тип предложения.)

*Кырга чыга һәм күзе караган якка таба акрын гына китеп бара.*

а) гади җөмлә; ә) тезмә кушма җөмлә; б) иярченле кушма җөмлә; в) катнаш кушма җөмлә

18. Җөмләдә тыныш билгеләре дөрес куелган очракны күрсәтегез.

(В каком варианте знаки препинания проставлены правильно?)

*Ир кеше (1) калын киемнән булуга карамастан (2) җитез генә иярга күтәрелде (3) өзәнгеләрен рәтләде (И.Сәлахов)*

а) өтер, өтер, өтер; ә) ике нокта, өтер, сызык; б) өтер, өтер, ике нокта; в) өтер, өтер, ике нокта.

19. *Чаңгыда шуу* сүтезмәсе кайсы төркемгә карый? (какой группе относится данное словосочетание?)

а) исем сүтезмә; ә) фигыль сүтезмә; б) алмашлык сүтезмә; в) сыйфат сүтезмә

20. Җөмләнең төрен билгеләгез. (Определите тип предложения.)

*Шулай итеп, урак бетте, көз җитте (Г.Тукай)*

а) иярченле кушма җөмлә; ә) күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә; б) катнаш кушма җөмлә; в) тезмә кушма җөмлә.

21. Сүз ясагыч кушымчалар кайсы төркемдә бирелгән? (В какой группе расположены словообразующие аффиксы?)

а) -ның, -нең; -да, -дә; -ым,-ем; ә) -даш, -дәш; -чы, -че; -лык, -лек; б) -ган, -гән; -ды, -де; -ыр, -ер; в) -у, -ү; -ырга, -ергә; -гач, -гәч;

22. *Миләш чыпчыгы, мүк җиләге, бака яфрагы* сүзләре сүз ясалышының кайсы ысулына карый? (Каким способом образованы данные слова?)

а) сүзләрне кушу юлы белән; ә) сүзләргә кушымчалар өстәү юлы белән; б) сүзне кыскатру юлы белән; в) дөрес җавап юк.

23. Ясалышы ягыннан *егерме җиде* саны нинди төргә карый? (Какому типу словообразования относится приведенное числительное)

а) тамыр сан; ә) кушма сан; б) парлы сан; в) тезмә сан.

24. Фигыль ясагыч кушымчаларны күрсәтегез. (Выделите словообразовательные аффиксы глагола.)

а) -ла/-лә; -лан/-лән; -а/-ә; ә) -лык/-лек; -даш/-дәш; -сыз/-сез; б) -лы/-ле; -гы/-ге; -сыз/-сез; в) -ча, -чә; -дай, -дәй; -га, -гә.

25. Төзелеше буенча *очсыз-кырыйсыз* сүзе кайсы төргә карый? (Какому типу относится слово *очсыз-кырыйсыз?)*

а) тамыр сүз; ә) ясалма сүз; б) кушма сүз; в) парлы сүз.

**III** Мәкальләрне язып бетерегез. **(5 балл)**

1. Аз сөйләсәң, ... 2. Кем эшләми, ... 3. Тырышкан табар, ... 4. Кем арбасына утырсаң, ... 5. Арбаны кыштан, ... .

**IV** Тәкъдим ителгән сүзләрнең антонимнарын языгыз. **(5 балл)**

җылы, таза, эшчән, юмарт, кыйбат, авыр, коры, ерак, акыллы, ачык

**V.** Һәр очракка бишәр сүз языгыз.**(6 балл)**

1. Татар теленең үз сүзләре ...
2. Гарәп-фарсы сүзләре ...
3. Рус һәм башка сүзләре ...

**VI.** Нокталар урынына тиешле сүзләр языгыз (Вставьте вместо точек нужные слова.) **(10 баллов)**

1. О, ө, у, ү авазлары .... сузыклар дип атала.

2. Сузыкларның сүз эчендә калынлыкта-нечкәлектә ярашуы .... законы дип атала.
3. *Матур, гүзәл, күркәле* сүзләре ... дип атала.
4. Тел белеменең “Морфология” тармагы ... ... өйрәнә.
5. Хәл фигыль ..., ..., ... , ..., ..., ... кушымчалары ярдәмендә ясала.
6. Сыйфат фигыль үзендә ике сүз төркеме ... һәм ... билгеләрен берләштерә.
7. *Кадерле, бәхетле, тәмле* сыйфатлары .... ысулы белән ясалган.
8. Кушма җөмлә .... яки ... гади җөмләдән тора.
9. Тиешле бәйлекләрне куеп, җөмләне тутырып языгыз. *Имтиханнар беткәннән .... дусларым ... кафега кердек.*
10 Бер генә баш кисәге булган җөмлә .... җөмлә дип атала.

**VII.** Хикәядән соң булган тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа. **(За каждый правильный ответ 1 балл =17 баллов)**

**Якты күл**

1) Билал берүзе урман сукмагыннан бара. 2) Олы юлны калдырып, юри тар сукмактан кереп киттек. 3) Адашмас, югалмас әле, урман адаштырмый ул, йөри белсәң. 4) Киресенчә, авыл малайлары – табигатьтә егетләр – шәһәрнең төз-төз урамнарында адашалар күп вакытта. 5) Ә урман юллары адаштырмый аларны, чөнки табигатьтә, урманда алдау, хәйлә дигән яман нәрсә юк, анда барысы да ачык, күңелгә якын. 6) Бөек табигыйлек монда.

7) Сукмак борылып-борылып барды да зур булмаган бер ачыклыкка килеп чыкты. 8) Ә ул ачыклык күлгә килеп ялгана икән. 9) Менә нинди икән ул Якты күл! 10) Исеме җисеменә бик тә туры килә шул. 11) Шушы ямьле урман уртасындагы сихри зәңгәр күз шикелле икән ул! 12) Эчкерсез күңелләрнең яктылыгы шикелле икән ул. 13) Мөлдерәмә тулы икән. 14) Ап-ак каенлы ярлары, бу кадерле байлыкны ничек сакларга дигәндәй, тыныч кына уйга талган.

15) Билал, күл буена чыккач, башта бөтенләй туктап калды. 16)Ул шушы гүзәллекне озаклап күзәтте. 17) Күл өстенең ышанып булмастай зәңгәр тигезлеге вакыты-вакыты белән хәтта аны үзенә тарткан төсле иде. (*М.Вәли*) (150 сүз)

1. Аваз һәм хәреф саннары туры килмәгән сүзләре булган җөмләне билгеләгез. (Определите предложение, где не совпадают звуки и буквы.)
а) 1 ә) 5 б) 10 в) 15.
2. Әйтелештә ирен гармониясенә буйсынган сүзләре булган җөмләне билгеләгез. (В каком из предложений имеются слова с губной гармонией в произношении)
а) 3 ә) 5 б) 7 в) 8.
3. Басымның беренче иҗеккә төшкән очрагын күрсәтегез. (Укажите предложение, где есть слово с ударением на первом слоге.)
а) 1 ә) 8 б) 2 в) 6.
4. Әйтелеш белән язылышта аерма булган сүзле җөмләне күрсәтегез. (В каком из предложений есть слово, различающееся по написанию и произношению?)
а) 8 ә) 9 б) 14 в) 10.
5. Гарәп алынмалары булган җөмләне билгеләгез. (Определите предложение, где имеются арабские заимствования.)
а) 2 ә) 8 б) 7 б) 10
6. Күчерелмә мәгънәдәге тезмә сүз кулланылган җөмләне билгеләгез. (В каком из предложений употреблено составное слово в переносном значении?)
а) 6 ә) 4 б) 9 в) 14
7. Ялгызлык исем кулланылган җөмләне табыгыз. (Определите предложение, где имеется имя собственное.)
а) 3 ә) 5 б) 9 в) 11
8. Фразеологик әйтелмә булган җөмләне билгеләгез. (Выделите предложение, где имеется фразеологизм)
а) 10 ә) 15 б) 8 в) 9
9. Билгесез киләчәк заман хикәя фигыль (юклык формасында) кулланылган җөмләне табыгыз. (Найдите предложение, где употреблен глагол в неопределенном будущем времени)
а) 3 ә) 5 б) 10 в) 15
10. Кушма рәвеш кайсы җөмләдә кулланылган? (В каком из предложений употреблено сложное наречие?)
а) 1 ә) 6 б) 9 в) 10
11. Ясалма сыйфатлар кулланылган җөмләне билгеләгез. (Определите предложение, где есть прилагательное, образованное при помощи словообразовательных аффиксов.)
а) 5 ә) 8 б) 10 в) 11

12. Кайсы җөмләдә бәйлекләр кулланылган? (В каком из предложений употреблены послелоги?)

а) 1 ә) 2 б) 8 в) 17

13. Дүрт морфемадан торган сүз кайсы җөмләдә кулланылган? (В каком из предложений имеется слово, состоящее из четырех морфем?)

а) 4 ә) 6 б) 8 в) 12

14. Кушма фигыль-хәбәре булган җөмләне билгеләгез. (Определите предложение, где имеется сложное глагольное сказуемое.)

а) 1 ә) 2 б) 5 в) 12.

15. Аныклагычы булган җөмләне табыгыз. (Определите предложение, где представлено уточнение.)

а) 3 ә) 4 б) 7 в) 12.

16. Җөмләләр арасында тиңдәш иярүле күп иярченле катнаш кушма җөмләне билгеләгез.

а) 5 ә) 6 б) 7 в) 14.

17. Ким җөмләне билгеләгез.

а) 7 ә) 8 б) 13 в) 17.

**VIII** Өтер куюның 5 очрагын санагыз. Тексттан (“Якты күл”) туры килгән җөмләләрнең номерларын күрсәтегез; үз мисалларыгызны өстәгез **(5 балл)**

**IX** Тәкъдим ителгән җөмләгә карата биремнәрне үтәгез. – Выполните задания. **(12 балл)**

*Мәктәп сукмагын урталай бүлеп аккан Киндерле елгасы ярына килеп җиткәч Наил тимер күпернең аркавына сөялеп ташу акканны күзәтеп торды. (К.Кәримов)*

1. Тыныш билгеләрен куегыз һәм аңлатыгыз (поставьте и объясните знаки препинания). **(2 балл)**
2. Җөмләнең төрен билгеләгез, схемасын сызыгыз (определите тип предложения, начертите схему). **(2 балл)**
3. *Елгасы* сүзенә фонетик анализ ясагыз. **(2 балл)**
4. *Сөялеп, сукмагын, урталай* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. **(3 балл)**
5. *Мәктәп* сүзенә лексик анализ ясагыз. **(2 балл)**
6. *Урталай* сүзен сүз составы буенча тикшерегез. **(1 балл)**

**X.** Гади җөмләгә тулы характеристика бирегез. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз. (Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению.) **(5 баллов)**

*Мин яшел яфрак, каен агачында туып, берничә ай яшәдем; язын табигатьнең уянуына сокландым, җәен кызу кояш нурларында иркәләндем (Сөмбел Гаффарова)*

**Ответы**
**межрегиональной предметной олимпиады Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год**

**9 - класс**

**I.** За перевод текста на татарский язык – **7 баллов**, за продолжение сказки в форме ответа(ов) героев – **3 балла**, всего **10 баллов**.

**II.** За каждый один правильный ответ 25-и тестов **по 1 баллу**, всего **25 баллов**. **Ответы представлены в левом столбике таблицы № 1.**

**Таблица №1**

| **II.** ***Ответы тестов*** | | | | **VII.** Ответы тестов по тексту (За каждый правильный ответ по 1 баллу) Всего 17 баллов | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Б** | 16 | **Б** | 1 | **Ә** |
| 2 | **А** | 17 | **Б** | 2 | **Б** |
| 3 | **Ә** | 18 | **А** | 3 | **А** |
| 4 | **Ә** | 19 | **Ә** | 4 | **Б** |
| 5 | **Ә** | 20 | **В** | 5 | **Б** |
| 6 | **Ә** | 21 | **Ә** | 6 | **В** |
| 7 | **Ә** | 22 | **А** | 7 | **Б** |
| 8 | **В** | 23 | **В** | 8 | **А** |
| 9 | **В** | 24 | **А** | 9 | **А** |
| 10 | **Ә** | 25 | **В** | 10 | **А** |
| 11 | **Б** | | | 11 | **В** |
| 12 | **Б** | | | 12 | **В** |
| 13 | **Б** | | | 13 | **А** |
| 14 | **В** | | | 14 | **Ә** |
| 15 | **Б** | | | 15 | **Ә** |
| | | | | 16 | **А** |
| | | | | 17 | **Б** |

**III.** Допишите пословицы **(5 баллов)**

1. Аз сөйләсәң, …. 2. Кем эшләми, …. 3. Тырышкан табар, …. 4. Кем арбасына утырсаң, ….. 5. Арбаны кыштан, …..

**IV**. Подберите антонимы к данным словам словам **(5 баллов)**

Җылы - холодный, таза - худой, эшчән - ленивый, юмарт - скупой, кыйбат - дешевый, авыр - легкий, коры - мокрый, ерак - близкий, акыллы – неумный, ачык – закрытый.

**V.** Напишите по 5 слов на каждый случай **(6 баллов).**

1. Исконно-татарские слова: баш, кул, ишек, ачкыч, каен

2. Арабо-персидские заимствования: җәмәгать, иътибар, каләм, дивар, мәгариф

3. Слова заимствованные через русский язык: вагон, самолет, телефон, ваза, пенал

**VI.** Вставьте вместо точек нужные слова. **(10 баллов)**

| | |
|---|---|
| 1 | огубление |
| 2 | сингармонизм |
| 3 | синоним |
| 4 | Частей речи |
| 5 | -ып/-еп/-п; -а/-ә, -ый/-и; -гач/-гәч; -ганчы/-гәнче |
| 6 | причастие |
| 7 | аффиксация |
| 8 | ике, берничә |
| 9 | послеслоги |
| 10 | односоставной |

**VII.** Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа “Светлое озеро”. За каждый правильный ответ 1 балл (17 баллов). (**Ответы представлены в правом столбике таблицы № 1.)**

**VIII.** За выделение из текста (“Светлое озеро”) 5 предложений, где предполагается ставить запятые: по 1 баллу, (всего 5 баллов). Можно добавить свои примеры.

1. Однородные члены (предложения): 3-е, 5-е предложения.
2. Обособленные члены: 3-е, 5-е, 14-е предложения.
3. Выделение вводных слов: 4-е предложение.
4. Сложноподчиненные предложения : 3-е, 5-е предложения.
5. сложносочиненные предложения:

**IX** Выполните задания. **( Всего 12 баллов)**

*Мәктәп сукмагын урталай бүлеп аккан Киндерле елгасы ярына килеп җиткәч (,) Наил (,) тимер күпернең аркавына сөялеп (,) ташу акканны күзәтеп торды. (К.Кәримов)*

1. Тыныш билгеләрен куегыз һәм аңлатыгыз. (Ставьте знаки препинания.) **(2 балл)**
2. Җөмләнең схемасын сызыгыз (Начертите схему предложения.) **(2 балл)**
3. *Елгасы* сүзенә фонетик анализ ясагыз (Фонетический анализ слова *елгасы.)* **(2 балл)**
4. *Сөялеп, сукмагын* сүзләренә морфологик анализ ясагыз (Морфологический анализ слов *сөялеп, сукмагын).* **(3 балл)**
5. *Мәктәп* сүзенә лексик анализ ясагыз (Лексический анализ слова *мәктәп.*) **(2 балл)**
6. *Урталай* сүзен сүз составы буенча тикшерегез (Разбор слова *урталай* по составу.) **(1 балл)**

**X.** Гади җөмләгә тулы характеристика бирегез. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз (Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению.) **(5 балл)**

*Мин яшел яфрак, каен агачында туып, берничә яшәдем; язын табигатьнең уянуына сокландым, җәен кызу кояш нурларында иркәләндем (Сөмбел Гаффарова)*

***Исправления не допускаются!***

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год**
**10 класс**

**Шифр_____** **Итоговой балл ___ ________**подпись предс. жюри

I. Текстны тәрҗемә итегез һәм дәвам итеп языгыз (8-10 җөмлә). Сүзлекләр төзү белән шөгыльләнгән 2 галимне атагыз. – Переведите на русский язык и продолжите. Назовите двух ученых, занимающихся составлением словарей. **(11 баллов)**

Человек не может хранить в памяти все: события прошлого и настоящего, даты, факты, цифры, названия. Имена. И когда нужен ответ на вопрос или какая-то справка, на помощь приходят словари.

Это книги скупые и щедрые одновременно: в них нет ничего лишнего и есть много нужного. Одни подскажут вам названия рек, городов, морей, гор. Другие расскажут о болезнях и их лечении. Третьи – о растениях или машинах. Есть словари, которые расскажут, что значит незнакомое слово, откуда оно пришло.

В словарях – знания, накопленные многими поколениями. Эти книги учат нас, сберегают наше время и силы. Помогают избегать ошибок в той или иной работе.

II. Фразеологизмнарны татарчага тәрҗемә итегез. – Переведите на русский язык. **(10 баллов)**

в мгновение ока, обвести вокруг пальца, как с гуся вода, пальчики оближешь, кот наплакал, мастер на все руки, между ними кошка пробежала, кожа да кости, одного поля ягода, глаза на мокром месте

III. Сөйләм хаталарын төзәтегез. – Исправьте речевые ошибки. **(6 баллов)**

1. Тәрәзә каршында машина басып тора. 2. Гарифуллин авырта. 3. Юан дәфтәрнең бәясе ике тапкыр кыйммәтрәк булып чыкты. 4. Әлфия һәм Зөлфия тырышып укыйлар. 5. Җыелыш җансыз үтте. 6. Конкрет кешеләр адресына тәнкыйть булмады.

IV. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. **(25 баллов)**

1. Тартык авазлар чиратлашу күзәтелгән мәкальне табыгыз (Найдите пословицу, в которой наблюдается чередование согласных звуков).

а) Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы; ә) Әдәпленең күлмәге сәдәпле, үзе матур гадәтле; б) Акыллы сүзен “мин” дип башламый; в) Мактану хур итә, тыйнаклыкка ни җитә.

2. Ябык иҗекләрдән генә торган сүзләр рәтен билгеләгез (Отметьте ряд слов, состоящих только из закрытых слогов).

а) барганга, саклагыз, егерме; ә) сакланган, сыйфатлар, туйганнар; б) өчпочмак, бишбалта, рәвешләр; в) ысуллар, исемнәр, ярканат.

3. Күп нокталар урынына ***һ*** хәрефе языла торган сүзләр рәтен күрсәтегез (Укажите ряд слов, в которых вместо точек необходимо написать букву ***һ).***

а) зин ... ар, мәш ... үр, мә ... абәт; ә) сәя ... әт, шә ... әр, җәрә ... әт; б) и ... ътибар, ни ... аять, һәр ... әлдә; в) ... әтер, бә ... етле, ... әлакәт.

4. Әйтелеше белән язылышы туры килми торган сүзләр рәтен табыгыз (Обозначьте ряд слов, в которых написание не соответствует произношению).

а) бәхет, рөхсәт, көннәр; ә) көләч, йомыш, такта; б) әнкәй, унбиш, соңгы; в) сорау, кайткан, чимал.

5. “***Ирен-ирен, шаулы, йомык, саңгырау тартык***” билгеләмәсенә туры килгән авазы булган сүзне билгеләгез (Отметьте слова, в котором присутствует звук, подходящий под описание «***губно-губной, шумный, закрытый, глухой согласный звук***»).

а) камышлар; ә) каплаган; б) башыннан; в) тауларда.

6. Яңа сүзләрдән торган төркемне билгеләгез (Отметьте ряд слов, состоящих из неологизмов).

а) район, шәһәр, өлкә; ә) рейтинг, шопинг, бейджик; б) универмаг, эскалатор, гардероб; в) комсомол, совхоз, БАМ.

7. Ялгыш тәрҗемәне табыгыз (Найдите неправильный перевод).

а) предендент победы – җиңү дәгъвачысы; ә) индивидуальный подход – аерым якын килү; б) представитель страны – ил вәкаләте; в) столица республики – җөмһүрият мәркәзе.

8. Шигырь юлларыннан омонимнарны табып, астына сызыгыз, төрен билгеләгез (Найдите омонимы, подчеркните их, определите вид).

*Салават күперен күрдем,*
*Шундый матур буялган!*
*Ялганын да ялган инде,*
*Ләкин матур бу ялган.* Ш.Галиев

а) омоформа; ә) омофон; б) омограф; в) пароним.

9. Фразеологик антонимнарны билгеләгез (Обозначьте фразеологические антонимы)

а) теле авызына сыймау, авыз еру; ә) уртак тел табу, борчак пешмәү; б) тишек авыз, күз салу; в) телсез калу, баш вату.

10. «**Зур**» сүзе күчерелмә мәгънәдә килгән җөмләне билгеләгез (Обозначьте предложение, в котором слово «**зур**» употреблено в переносном значении).

а) Зур куак кинәт ботакларын селкеп куйды (Д.Аппакова); ә) Алдан килгән атның муенына зур сөлге урадылар (Р.Мөхәммәдиев); б) Калган балалары зур кеше булдылар (Ш.Хәсәнов); в) Менә өй эче. Ап-ак зур мич, кечкенә тәрәзәләр (Ә.Еники).

11. Модальлек кушымчалары гына була торган сүз төркемнәрен күрсәтегез (Укажите части речи, которые могут иметь лишь аффиксы модальности).

а) исемнәр, сыйфатлар, фигыльләр; ә) саннар, рәвешләр, сыйфатлар; б) аваз ияртемнәре, алмашлыклар, бәйлекләр; в) кисәкчәләр, ымлыклар, теркәгечләр.

12. "**Кешелеклелек**" сүзенең нигезе дөрес билгеләнгән җавапны күрсәтегез (Укажите ответ, в котором правильно обозначена основа слова).

а) кеше; ә) кешелек; б) кешелекле; в) кешелеклелек.

13. Ясагыч кушымчалар ярдәмендә ясалган сүзләр рәтен билгеләгез (Обозначьте ряд слов, образованных при помощи словообразовательных аффиксов).

а) чирәм, көчек, капка; ә) бәрәңге, көзгегә, җирләр; б) кичке, кышын, урманчының;
в) аккош, бала-чага, кура җиләге.

14. Сүзнең тамыры дөрес күрсәтелмәгән мисалны табыгыз (Найдите слово, в котором неверно указан корень слова).

а) янында (яны); ә) сабакташ (сабак); б) далаларда (дала); в) матурлыгы (матур)

15. Саннарның ясалу ысуллары арасында күрсәтелгән ялгыш җавапны билгеләгез (Укажите неверный ответ в перечне способов образования имен числительных).

а) сүзләрне тезү ысулы белән; ә) сүзләрне кушу ысулы белән; б) сүзләрне парлау ысулы белән; в) ясагыч кушымча ялгау ысулы белән.

16. Җыю саны кергән җөмләне билгеләгез (Обозначьте предложение, в составе которого есть собирательное числительное).

а) Митингка меңнәрчә кеше җыелган иде; ә) Без икәү иртән юлга чыктык; б) Сеңлем икенче сыйныфта укый; в) Концерт башланырга ун минут калды.

17. Җөмләдәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализ ясалган вариантны билгеләгез (Укажите вариант, в котором сделан правильный морфологический анализ выделенному слову).
*Идел-йортка килә яңгыр – тәрәзәгә* ***шыбыр-шыбыр*** *нидер сөйли...* (Р.Ә.)

а) аваз ияртеме, җөмләдә аергыч, парлы сүз; ә) рәвеш, җәмләдә рәвеш хәле, парлы сүз; б) аваз ияртеме, җәмләдә рәвеш хәле, парлы сүз; в) рәвеш, җөмләдә аергыч, парлы сүз.

18. ***әллә кем, алар, үз, монда, кемдер, кайсы*** алмашлыкларының төркемчәсе дөрес билгеләнгән рәтне күрсәтегез (Укажите ряд местоимений, где правильно указаны разряды местоимений).

а) сорау, билгесезлек, билгеләү, күрсәтү, сорау, билгесезлек; ә) билгесезлек, зат, күрсәтү, күрсәтү, билгесезлек сорау; б) билгесезлек, зат, билгеләү, күрсәтү, билгесезлек, сорау; в) билгеләү, зат, билгеләү, күрсәтү, билгесезлек, сорау.

19. Шигырьдә баш килештә килгән ничә сүз бар икәнен санагыз (Посчитайте, сколько в стихотворной строфе слов в именительном падеже)

Туган телең -
Бар тарихың
Чагыла торган тел бит,
Бүгенгең һәм киләчәгең
Сагында торган тел бит. (З.Нас.)

а) 4; ә) 5; б) 6; в) 7.

20. Төркемчәсе дөрес күрсәтелмәгән фигыльне билгеләгез (Укажите глагол, наклонение которого указано неверно).

а) барсын – боерык фигыль; ә) барасы – сыйфат фигыль; б) бармас – шарт фигыль;
в) бармаска – инфинитив.

21.Билгеләнгән җөмләгә дөрес билгеләмәне күрсәтегез (Укажите правильное определение выделенного предложения)
*Йортыгыз зурмы? –* ***Кечкенә*** (Т.Г.)

а) билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә; ә) фигыль җөмлә; б) ким җөмлә; в) билгесез үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.

22. Хәбәрлекнең санына карап, җөмләләрнең түбәндәге төрләре билгеләнә (Исходя из количества предикативности выделяются следующие типы предложений)

а) тулы һәм ким җөмләләр; ә) гади һәм кушма җөмләләр; б) җыйнак һәм җәенке җөмләләр; в) бер составлы һәм ике составлы җөмләләр.

23. Мәкальләр арасыннан бер составлы җөмләне билгелә (Отметьте пословицу, выраженную односоставным предложением)

а) Ике уйла, бер кис; ә) Тел кылычтан үткен; б) Туры сүз таш яра; в) Яхшы сүз балдан татлырак.

24. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән җавапны табыгыз (Найдите вариант, где правильно указан тип предложения).
*Йолдыз исе килгән беренче кар*
*Тамчы булып чәчләреңә ява* (М.Галиев)

а) гади; ә) тезмә кушма; б) иярченле кушма; в) катлаулы.

25. Җөмләләрне текст барлыкка килерлек итеп урнаштыру вариантын сайлагыз (Выберите вариант, по которому предложения составят текст).

1. Фатих Әмирхан – атаклы татар язучысы. 2. Тирә-якта тыз-быз килеп машиналар чаба, кешеләр каядыр ашыгалар. 3. Иң зур урамнарның берсе ул. 4. Мин урамда. 5. Исеме дә бик күркәм – Фатих Әмирхан урамы. 6. Шундый матур урамда яшәгәнемә шатланып, мин дә кешеләр агымына кушылам. 7. Бу урамны Казанда яшәүче һәркем белә.

а) 2, 4, 3, 7, 5, 1, 6; ә) 4, 3, 2, 5, 1, 6, 7; б) 4, 2, 7, 3, 5, 1, 6; в) 7, 4, 2, 3, 5, 1, 6.

V. Хикәядән соң булган тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа. **(За каждый правильный ответ 1 балл = 23 балла)**

**Чишмә янында**

1) Серле тынлык белән ак яктылык кына эленеп тора иде тирә-юньдә. 2) Рәхимҗан шулкадәр бәхетле һәм шат иде: ул җир белән күк, болыт белән көрт аермасын онытты.

3) Кинәт каядыр янәшәдә генә колагына серле аваз чалынгандай булды 4) Челтерәү авазы якыная төшкәч кенә, үзенең җирдә булуын, инеш буйлап чишмәгә баруын төшенде.

5) Җылы пар бөркеп, челтерәп агып яткан чишмәне күргәч, таң калды егет. 6) Гаҗәпләнмәслек тә түгел: бөтен дөнья - урам һәм тыкрыклар, инеш һәм су буйлары - кар астында йомылып яткан бер мәлдә чишмә күмелмичә калган 7) Нурлы аланлылар үзен күптән оныткан булуга карамастан, чишмә тирән кар катламын ярып чыккан: тибеп тора.

8) Җылынып киткәндәй булды егет, чөнки шаулап аккан салкын чишмә суыннан җылы пар бөркелә иде. 9) Егет, билдән карга батып, үргә чана тартып менгәндә дә, урамнардан үткәндә дә, шул җылылык аны озата барды.

10) Иртәгесен тагы су буена төште Рәхимҗан. 11) Ак кар өстендә күзгә күренер-күренмәс кенә рәшә йөгерә. 12) Никадәр матурлык монда!

(Р.Мөхәммәдиев) (143 сүз)

1. 8-12 нче җөмләләрдән ирен гармониясенә буйсынган 2 сүзе булган җөмләне табыгыз (Из 8-11 предложений найдите предложение в 2-х слова которого наблюдается губная гармония)

а) 8; ә) 12; б) 10; в) 11.

2. 1-4 нче җөмләләрдән сингармонизм законына буйсынмаган сүзләр булган җөмләне табыгыз ( Из указанных предложений найдите предложение со словами, в которых не наблюдается гармония гласных по рядам).

а) 1; ә) 2; б) 3; в) 4.

3. 1-7 нче җөмләләрдән кече тел ассимиляцясе һәм ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүзләре булган җөмләләрне табыгыз (Из указанных предложений найдите предложения со словами, в которых наблюдается увулярная и губная ассимиляция).

а) 4,7; ә) 3,6; б) 2,5; в) 1,3.

4. 1-5 нче җөмләләрдән басымы соңгы иҗеккә төшмәгән 2 сүзе булган җөмләне билгеләгез (Найдите предложение, в котором есть 2 слова, где ударение не падает на последний слог).

а) 5; ә) 2; б) 1; в) 3.

5. 1-4 нче җөмләләрдән синонимнар кергән җөмләне күрсәтегез (Из указанных предложений найдите предложение, в котором есть синонимы).

а) 1; ә) 2; б) 3) в) 4.

6. 11 нче җөмләдәге “**рәшә**” сүзенең тәрҗемәсен табыгыз (Найдите перевод слова “**рәшә**”).

а) утро; ә) туман; б) поземка; в) ветерок

7. 7 нче җөмләдән күчерелмә мәгънәле сүзне билгеләгез (Укажите слово с переносным значением в 7 предложении).

а) нурлы алан; ә) тирән кар; б) тибеп тора; в) кар катламы.

8. 6-9 нчы җөмләләр арасыннан антонимик мөнәсәбәткә кергән сүзләре булган җөмләне билгеләгез (Из указанных предложений найдите предложение, в котором есть слова-антонимы).

а) 6; ә) 7; б) 8; в) 9.

9. 1-2 нче җөмләләрдә ясалма нигезле сүзләрнең санын күрсәтегез (Укажите количество слов с производной основой в первых двух предложениях).

а) 6; ә) 7; б) 8; в) 9.

10. 8 нче җөмләдә 3 әр мәгънәле кисәге булган сүзләр санын күрсәтегез (Подсчитайте количество слов с 3-мя значимыми частями в 8-м предложении).

а) 3; ә) 4; б) 5; в) 6.

11. 5 нче җөмләдә бәйләгеч кушымчалары булган сүзләр санын күрсәтегез (Подсчитайте количество слов, в которых имеются и аффикс модальности, и связывающий аффикс).

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

12. 9 нчы җөмләдә һәм модальлек, һәм бәйләгеч кушымчалары булган сүзләр санын күрсәтегез. Подсчитайте количество слов, в которых имеются и аффиксы модальности, и связывающий аффикс.

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

13. 1-4 нче җөмләләрдән төшем килешендә килгән сүзләр кергәннәрен билгеләгез (Из указанных предложений найдите предложения, в которых есть слова в винительном падеже)

а) 1, 2; ә) 3, 4; б) 2, 4; в) 3, 1.

14. 8-12 нче җөмләләр арасыннан исемләшкән сыйфат фигыльләр булган җөмләне табыгыз (Найдите предложение, в котором есть субстантивированные причастия).

а) 8; ә) 9; б) 10; в) 10.

15. 4-12 нче җөмләләр арасыннан мөстәкыйль сүз төркемнәре генә кергән җөмләләрне табыгыз (Найдите предложения, в которых употреблены только самостоятельные части речи).

а) 4, 10; ә) 5, 12; б) 7, 9; в) 6, 11.

16. 3-10 нчы җөмләләрдән охшату-чагыштыру рәвешләре кергән җөмләләрне табыгыз (Найдите предложения, в которых употреблены наречия уподобления-сравнения).

а) 4 ,6; ә) 7, 9; б) 3, 8; в) 5, 10.

17. Тексттагы синтетик иярченле кушма җөмләләр санын билгеләгез (Обозначьте количество сложноподчиненных предложений с синтетической связью).

а) 3; ә) 4; б) 5; в) 6.

18. Тексттан иярчен күләм җөмләле кушма җөмләне табыгыз (Найдите предложение с придаточным степени).

а) 9; ә) 7; б) 2; в) 6.

19. Аерымланган хәлләр кергән җөмләләр рәтен билгеләгез (Найдите ряд предложений с обособленными обстоятельствами).

а) 4, 7; ә) 5, 8; б) 5, 9; в) 2, 4.

20. Татар телендә ике нокта белән билгеләнә торган тыныш билгесе куелуның 4 очрагын санагыз. Текстта шуларга мисал булса, шул җөмләнең номерын языгыз, булмаганына үз мисалыгызны язып куегыз (Перечислите 4 случая употребления двоеточия в татарском языке. Если в тексте есть примеры, укажите номер предложения, если нет – напишите свои предложения).

VI. Нокталар урынына тиешле сүзләр языгыз. – Вставьте вместо точек нужные слова. **(10 баллов)**

1. Татар алфавитындагы ... хәреф икешәр авазга билге булып йөри.
2. Сүзнең беренче иҗегендә [о, ө] сузыклары булса, аннан соңгы иҗекләрдәге “ы”, “е” хәрефләренең [о, ө] сузыгы итеп әйтелүе ... законының ... гармониясе дип атала.
3. Лексикологиянең сүзләрне җыю, аңлату, классификацияләү, сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә торган тармагы ... дип атала.
4. Кулланылыштан төшеп калган сүзләрне ... сүзләр дип атыйлар.
5. Ясагыч кушымчасы булган сүз ... нигезле сүз дип атала.
6. Исемнәрнең күплек кушымчасы ... кушымчасы, ә фигыльнең III зат күплек сан кушымчасы ... кушымча дип атала.
7. Затланышсыз фигыльләрнең ... икешәр сүз төркеме билгеләре бар.
8. Сан төркемчәләре арасыннан ... санының саналмышы булмый.
9. Иярчен җөмләләре бердән артык булган җөмлә ... кушма җөмлә дип атала.
10. Бәйләүче чарасы күрсәтү алмашлыгы белән белдерелә торган җөмләләр ... иярченле кушма җөмлә дип атала.

VII. Биремнәрне үтәгез. – Выполните задания. **(11 баллов)**

*Һәртөрле сайрар кошлар ыгы-зыгы килсә дә кул яссуыдай киң-киң яфраклары күп санлы ботак-тармаклары шаулап торса да бөреләр колакларына да элмәгән изрәп йоклый биргәннәр.* (Г.Хәсәнов).

1. Тыныш билгеләрен куеп аңлатыгыз (поставьте и объясните знаки препинания). (3 балл)
2. Җөмлә төрен билгеләгез, схемасын сызыгыз (определите тип предложения, начертите схему) (2 балл)
3. ***Бөреләр*** сүзенә фонетик анализ ясагыз. (1 балл)
4. ***Кул*** сүзенә лексик анализ ясагыз. (1 балл)
5. ***Колакларына*** сүзенең төзелешен, ясалышын аңлатма биреп (тамгалар белән генә түгел) тикшерегез. (1 балл)
6. ***Ботак-тармаклары, шаулап, күп санлы*** сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (3 балл)

VIII. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз; гади җөмләгә характеристика бирегез. – Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению. **(4 балла)**

*Кояш, агачлардагы һәр яфракка нуры белән кагылып, аларны алтын, гәрәбә, якут төсләргә кerткән.* (С.Гаффарова).

**Ответы**
**на задания межрегиональной олимпиады**
**Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год.**

**10ый класс**

I. За перевод текста – 5 баллов, за продолжение текста (8-10 предложений) – 4 балла, за фамилии двух ученых – составителей словарей – 2 балла. (например, проф. Ф.А.Ганиев, проф. Ф.С.Сафиуллина), всего 11 баллов.
II. За правильный перевод каждого фразеологизма – 1 балл. Всего 10 баллов.
III. За исправление речевой ошибки в каждом предложении – 1 балл. Всего 6 баллов.
IV. За каждый правильный ответ в 25 текстах – 1 балл. Всего 25 баллов.
V. По тексту «У родника» представлены 19 тестов – по 1 баллу. Всего 19 баллов. Ответы представлены в таблице №1.

| ответы тестов (1-25) | | | Ответы тестов по тексту «У родника» (1-19) | |
|---|---|---|---|---|
| 1-ә | 9-ә | 17-б | 1-в | 11-в |
| 2-ә | 10-б | 18-б | 2-ә | 12-ә |
| 3-а | 11-ә | 19-б | 3-ә | 13-б |
| 4-б | 12-в | 20-б | 4-в | 14-ә |
| 5-ә | 13-б | 21-б | 5-ә | 15-ә |
| 6-ә | 14-а | 22-ә | 6-ә | 16-б |
| 7-б | 15-в | 23-а | 7-б | 17-а |
| 8-ә | 16-ә | 24-б | 8-б | 18-б |
| | | 25-б | 9-б | 19-б |
| | | | 10-б | |

20е задание тоже по тексту, оценивается 4 баллами за перечисление или представление из текста каждого случая постановки двоеточия – 1 балл.
Двоеточие ставится:
1. Для обозначения средства выражения аналитической связи: 2е и 6е предложение.
2. Перед пояснением, если поясниимое слово выражено глаголом в функции сказуемого: 7е предложение.
3. После обобщающего слова, которое стоит перед однородными членами: *Бүген* ***барысы:*** *олысы, кечесе болынга чыкты.*
4. Перед прямой речью после слов автора: Татар халык мәкале: “теле барның иле бар”, - ди (Татарская народная пословица гласит: «У кого есть язык, у того есть государство»)

VI. В каждом из 10 предложений вписать пропущенное слово – 10 баллов, за каждое слово – 1 балл.
1. Слово **өч** – три.
2. Слова **сингармонизм** законының ирен гармониясе (губная гармония – второй вид закона сингармонизма).
3. Слово **Лексикография.**
4. Слово **архаизмнар** (архаизмы).

5. Слово **ясалма** (производная основа)
6. Слово **модальлек** (аффикс модальности) и **бәйләгеч** (связующий аффикс).
7. Слово **өчесендә** (в тринеспрягаемые формы глаголов – сыйфат фигыль) (имя действия).
8. Слово **"җыю"** (собирательное числительное).
9. Слово **күп иярченле** (многочленное сложноподчиненное)
10. Слово **аналитик** (аналитическая связь).

VII. Выполнение различных анализов в рамках одного предложения – 11 баллов.

1) Һәртөрле сайрар кошлар ыгы-зыгы килсә дә, 2) кул яссуыдай киң-киң яфраклары, күп санлы ботак-тармаклары шаулап торса да, 3) бөреләр колакларына да элмәгән: изрәп йоклый биргәннәр (Г.Хәсәнов)
1) даже если очень сильно суетились различные певчие птицы, 2) даже если беспрерывно шумели широкие листья, многочисленные ветки, 3) почки их даже не слышали: продолжали сладко спать (Г.Хасанов)
1) Первая и третья запятая поставлены после синтетических придаточных предложений, вторая запятая поставлена между однородными членами предложения, двоеточие поставлено перед пояснением, поясняемое слово которого выражено глаголом в функции сказуемого – 3 балла




Это многочленное сложное предложение с однородным соподчинением (2 балла)

3) Фонетический анализ слова *бөреләр* (1 балл)

Бөреләр [бө-рө-лэ'р]
В слове 3 слога (1,2 – открытые, 3-закрытый ударный).
7 букв (бэ, ө, эр, е, эль, ә, эр), 7 звуков (бөрөләр).
Гласные [ө, ө] – переднего ряда, среднего подъема, огубленные; [ә] – переднего ряда, нижнего подъема, неогубленный; наблюдаются оба вида закона сингармонизма – небная и губная.
Согласные [б], [р], [л], [р]: [б] – звонкий согласный, глухая пара [п], губно-губной, смычный; [р] – переднеязычный, сонорный, дрожащий; [л] – передязычный, сонорный, щелевой.
Произношение и правописание слова расходится ввиду присутствия губной гармонии закона сингармонизма.
4) Лексический анализ слова *кул* (1 балл)
Употреблено в прямом значении.

Антонима не имеет.
По происхождению общетюркское слово.
Активно употребляется в речи.
Употребляется в составе фразеологизмов: алтын куллы – золотые руки, кул сузымы җирдә – можно дотянуться рукой.

5) морфемный анализ слова колакларына (1 балл)
Колак – корень слова.
-лар – аффикс, выражающий отношение модальности, аффикс множественного числа;
-ы – аффикс, выражающий отношение, связывающий, принадлежности III лица;
-на – аффикс выражающий отношение, связывающий направительного (дательного) падежа.
Колак – корень слова.
6) Морфологический анализ слов ботак-тармаклары, шаулап, күпсанлы (3 балла).
Ботак-тармаклары – имя существительное, конкретное, нарицательное, множественного числа, притяжательность III лица единственного числа, именительного падежа, подлежащее, производная основа
Шаулап – деепричастие I формы, основной залог, утвердительный аспект, неспрягаемая форма, сказуемое придаточного предложения, производная основа.
Күпсанлы – имя прилагательное, определение, производная основа

VIII. Полная характеристика простого предложения – 4 балла.
Это простое, утвердительное, двусоставное, полное, осложненное деепричастным оборотом и однородными определениями предложение с прямым порядком слов (2 балла)

Кояш – подлежащее, кертқән – сказуемое, аларны, төсләргә - дополнение;
Алтын, гәрәбә, якут – определения;
Агачлардагы һәр яфракка нуры белән кагылып – деепричастный оборот (2 балла)

***Исправления не допускаются!***

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год**
**11 класс**

**Шифр_____** **Итоговой балл ___ ________**подпись предс. Жюри

I.Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндереп тәрҗемә итегез һәм крестьян исеменнән табышмакны чишеп, әкиятне дәвам итегез. - Переведите прямую речь на татарский язык в форме косвенной речи; разгадав загадку, продолжите сказку (10-12 предл.). **(10 баллов)**

Мудрый крестьянин

Однажды король поехал на охоту и увидел крестьянин, который работал на своем поле.

Король подозвал его и спросил:

- Сколько ты зарабатываешь в день?

- Четыре монеты, король, - ответил крестьянин.

И что же ты делаешь этими четырьмя монетами?

-Первую,- ответил крестьянин, - съедаю, вторую откладываю впрок, третью отдаю обратно, а четвертой потчую дорогих гостей.

Король поехал дальше, хотя этот ответ и показался ему очень странным. Думал он, думал, но так ничего и не смог придумать. Поскакал он тогда обратно и потребовал у крестьянина ответа.

II. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез. – Найдите в каждом тесте один правильный ответ. **(25 баллов)**

1. Татарлар кириллицага нигезләнгән алфавитны рәсми рәвештә кайчан файдалана башлый? (Когда начали использовать кириллицу в татарской графике?)

а) 11 нче гасырда; ә) 10 нчы гасырда; б) 21 нче гасырда; в) 20 нче гасырда.

2. Бу нинди сүзләр? (Это какие слова?)

Алсу-алсу, Панама- панама, Бостон-бостон.

а) омографлар; ә) омофоннар; б) омоформалар; в) дөрес җавап бирелмәгән.

3. Бирелгән сүзләрнең төрен күрсәтегез (укажите, какие даны слова?): иртәдән кичкә кадәр, күзгә-күз сөйләшү, әрәм-шәрәм итү, Киек каз юлы.

а) тезмә сүзләр; ә) сүзтезмәләр; б) кушма сүзләр; в) җөмләләр.

4. Аналитик иярчен җөмләләрне баш җөмләгә бәйләүдә катнашмаучы чараны күрсәтегез. (Какое средство, указанное ниже, не связывает аналитическое придаточное к главному?)

а) күтәрү интонациясе; ә) бәйлек һәм бәйлек сүзләр; б) ияртүче теркәгечләр; в) теркәгеч сүзләр.

5. Ялгыш билгеләнгән сүз төркемен күрсәтегез. (Найдите неправильное обозначение части речи.)

а) баздан – исем; ә) җәйге – рәвеш; б) күтәреп – хәл фигыль; в) һич – инкарь кисәкчәсе.

6. Сузык авазлары ягыннан караганда, аерылып торган сүз кайсы җөмләдә бар? (В каком предложении имеется слово, отличающееся гласными звуками?)

а) Мин өйдә әниемә булышам. ә) Әлфия эшкә китте. б) Кеше иптәшенә ярдәм итәргә тиеш. в) Сез өегездә нинди әйберләр төзәттегез?

7. Тартык авазлары ягыннан караганда, аерылып торган сүз кайсы җөмләдә бар? (В каком предложении имеется слово, отличающееся согласными звуками?)

а) Маннур авылда балаларга белем бирә. ә) Балам, багалмам, - диде әтисе Гөлнурга. б) Белемле меңне егар. в) Булганнан бар да була.

8. Басым сүз ахырына куелмый торган сүзләрне билгеләгез. (Укажите слова с ударением не на конце слова.)

а) сүзчәнлек, өлгер; ә) акрын, бераз; б) баргансың, килмәсә; в) ихтирам, сабыр.

9. Иҗек калыплары ялгыш күрсәтелгән сүзне күрсәтегез. (Найдите слово с неправильным слогоделением.)

а) СТ-ТС: ал-са; ә) СТ-СТ: ач-ык; б) ТСТ-ТС: бал-лы; в)ТС-ТС-ТС: ю-ма-ды.

10. Нигезе ялгыш билгеләнгән сүзләрне күрсәтегез. (Найдите слова с неправильным обозначением основы.)

а) эшчәнлек-тә, татарча-га; ә) барма-сын, җилләр-не; б) күңелле-рәк, яхшылык-ның; в) кызыксын-ган, яхшыр-ды.

11. Сызыкча аша язылырга тиешле сүзләрне билгеләгез. (Какие слова пишутся через дефис?)

а) биш алты, җиде сигез; ә) куе зәңгәр, артык җитди; б) сыек яшел, аеруча ямьле; в) шундый зур, бик иртә.

12. Мәгънәле кисәкләргә ялгыш бүленгән сүзләрне табыгыз. (Найдите слова с неправильным обозначением значимых частей.)

а) карлыган-дай, киң-лек-кә; ә) кара-гач, сөз-геч; б) саб-ын, җит-ен; в) боз-лан-ды, җир-дә-ге.

13. Бәйләгеч кушымчалары булган сүзләрне күрсәтегез. (Какие слова имеют присоединяющие аффиксы?)

а) һәйкәл-нең, күр-еп; ә) бәйрәм-нәр, биш-лек; б) җиде-нче, кыз-чык; в) укы-ячак, хәйлә-ле.

14. Модальлек кушымчалары булган сүзләрне табыгыз. (Какие слова имеют аффиксы модальности?)

а) сөлге-се, юл-даш-ның; ә) сөенеч-кә, кыз-ны; б) көт-кәч, төр-ү; в) югары-рак, биш-әү.

15. Тамыры ялгыш билгеләнгән сүзләрне күрсәтегез. (Найдите слова с неправильным обозначением корня.)

а) кил-ерсең, мәктәп-ләрдә; ә) кием-е, белгеч-не; б) тый-наклыктан, эш-ләсә; в) тырыш-лыкка, тигез-лектә.

16. Рәвеш ясамый торган кушымчаларны күрсәтегез. (Найдите аффиксы, не образующие наречия.)

а) –ын, -ен; -лап, -ләп; ә) –ча, -чә; -дай, -дәй; б) –ла, -лә; -лан, -лән; в) –лата, -ләтә; -тай, -тәй.

17. Хаталы сүзтезмәне күрсәтегез.(Найдите неправильное словосочетание.)

а) таяк сындыру; ә) агач сындыру; б) җеп сындыру; в) такта сындыру.

18. Бирелгән сүзләрдә ирен ассимиляциясе күзәтелмәгән очракны билгеләгез. (В каком слове не наблюдается губная ассимиляция?)

а) урамнар; ә) Донбасс; б) төнбоек;в) унбиш.

19. Татар тел белемендә фонетика өлкәсендә эшләгән галимнәрне күрсәтегез. ( Кто из ученых занимался изучением фонетики татарского языка?)

а) Ф.Ә.Ганиев, Ф.С.Сафиуллина; ә) М.З.Зәкиев, Ф.Ф.Харисов; б) Г.Шәрәф, Х.Х.Сәлимов; в) Г.Х.Алпаров, В.Х.Хаков.

20. *Язгы ташуларда аккан бозга басып, <u>икәү</u> килә елга буйлатып (И.Юзеев)* җөмләсендәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны табыгыз. (Найдите правильный морфологический анализ выделенного слова.)

а) Алмашлык, баш килештә, берлек санда, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. ә) Җыю саны, исемләшкән, баш килештә, берлек санда, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. б) Җыю саны, баш килештә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. в) Билгесезлек алмашлыгы, баш килештә, берлек санда, тартым белән төрләнмәгән, җөмләдә тәмамлык булып килгән, тамыр сүз.

21. *Мәхәббәт ул <u>үзе</u> иске нәрсә...(Һ.Такташ)* җөмләсендәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны күрсәтегез. (Найдите правильный морфологический анализ выделенного слова.)

а) Зат алмашлыгы, баш килештә, берлек санда, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. ә) Билгеләү алмашлыгы, баш килештә, берлек санда, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. б) Билгеләү алмашлыгы, баш килештә, берлек санда, III зат тартым белән төрләнгән, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз. в) Билгеләү алмашлыгы, баш килештә, берлек санда, III зат тартым белән төрләнгән, җөмләдә аныклагыч булып килгән, тамыр сүз.

22. *Урамдагы трамвай тавышы <u>бер</u> акрынаеп, <u>бер</u> көчәеп ишетелә иде. (Г.Әпсәләмов)* җөмләсендә билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны күрсәтегез. (Найдитее правильный морфологический анализ выделенного слова.)

а) Микъдар саны, тиңдәш кисәкләр янында бүлүче теркәгеч урынында кулланылган. ә) Микъдар саны, фигыльне ачыклаган, җөмләдә хәл булып килгән. б) Микъдар саны, исемләшкән, җөмләдә хәл булып килгән. в) Микъдар саны, берлек санда, баш килештә, җөмләдә күләм хәле булып килгән.

23. *Бу көмеш <u>кыңгырауларның</u> кечке яңгыраулары әллә нишләтә күңелне... (Ф.Кәрим)* җөмләсендәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны табыгыз. (Найдите правильный морфологический анализ выделенного слова.)

а) Исем, уртаклык исем, күплек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә, җөмләдә аергыч булып килгән, тамыр сүз. ә) Исем, уртаклык исем, күплек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә, җөмләдә тәмамлык булып килгән, тамыр сүз. б) Исем фигыль, күплек санда, тартым белән төрләнмәгән, иялек килешендә, җөмләдә аергыч булып килгән, ясалма сүз. в) Исем фигыль, барлыкта, күплек санда, иялек килешендә, җөмләдә ия булып килгән, тамыр сүз.

24. *<u>Шигъремдәге</u> чынлык, ут һәм сөю – яшәвемнең бөтен мәгънәсе. (М.Җәлил)* җөмләсендәге билгеләнгән сүзгә дөрес морфологик анализны билгеләгез. (Найдите правильный морфологический анализ выделенного слова.)

а) Исем, уртаклык исем, баш килештә, берлек санда, III зат берлек сан тартымлы, җөмләдә аергыч булып килгән, ясалма сүз. ә) Сыйфат, гади дәрәҗәдә, исемләшкән, урын-вакыт килешендә, җөмләдә аергыч булып килгән, тамыр сүз. б) Нисби сыйфат, гади дәрәҗәдә, җөмләдә аергыч булып килгән, ясалма сүз. в) Рәвеш, вакыт рәвеше, гади дәрәҗәдә, җөмләдә вакыт хәле, ясалма сүз.

25. Чагыштырмача кыска сузыклар гына булган рәтне билгеләгез. (Определите краткие гласные татарского языка.)

а) [о], [ы], [э]; ә) [а], [ә], [ө] ; б) [у], [ү], [ә]; в) [и], [ы]. [э].

III. Фразеологизмнарның мәгънәләрен бер сүз белән языгыз. – Значение фразеологизмов напишите одним словом. **(10 баллов)**

табан ялтырату, борчак пешмәү, утлы табага бастыру, бармак аша карау, сәлам кыстыру, ут йоту, авыз еру, трай тибү, су кебек эчү, сүзгә кесәгә кермәү

IV. Сөйләм хаталарын төзәтегез. – Исправьте речевые ошибки. **(6 баллов)**

1. План тулы үтәлде. 2. Бүген радиодан орденлы чемпион сөйләде. 3. Бу мәсьәләне аңлаешлы формаларда аңлатып бирү сорала. 4. Хәзер сәгать ничә микән? 5. Бөтен дөнья халыклары зур вакыйгалар бусагасында тора. 6. Үз фикереңне ана һәм рус телләрендә грамоталы, аңлаешлы, дөрес итеп сөйли һәм яза белү – хәзерге заман кешесенең культурасын билгели торган сыйфатларның берсе.

V. Хикәядән соң булган тест биремнәрен үтәгез. – Выполните тестовые задания, приведенные после рассказа. **(За каждый правильный ответ 1 балл = 24 балла)**

**Гаилә балага нәрсә бирә?**

1) Әйбәт гаилә балаларга нәрсә бирә ала? 2) Барыннан да элек, ул сабыйлыкның алтын чорын бүләк итә, ә бу, мөгаен, бөтен гомернең иң бәхетле чорыдыр. 3) Сабый чак – кеше гомеренең кабатланмас бер чоры, һәм гаилә сабыйлар үсешендә искиткеч зур роль уйный.

4) Үсемлекнең тиешенчә үсүе өчен, кояш нуры кирәк булган кебек, балага да әти-әни мәхәббәте яктысы кирәк. 5) Нәкъ менә шул мәхәббәт һәм ата-ананың шәхси тәрбиясе – кешене кеше итә торган төп этәргеч.

6) Нәкъ менә гаиләдә, мәктәпкә кадәрге чорда, шәхеснең иң мөһим психологик нигезләре барлыккка килә. 7) Шул вакытта безнең психикабызның иң озын гомерле сыйфатлары, тормышка эмоциональ һәм әхлакый мөнәсәбәтнең нигезләре өлгерә башлый. 8) Соңрак алар өстенә тормышның башка йогынтылары катлам-катлам булып урнашачак, әммә әлеге йогынтыларны үзләштерү, аларны үз гамәлләреңнең этәргеченә әверелдерү – болар барысы да бала шәхесенең гаиләдә салынган төп нигезенә бәйле булачак.

9) Ата-аналар баланың рухи дөньясын формалаштыралар, дөньяны танып белергә, тормышны аңларга өйрәтәләр. 10) Шуңа күрә гаиләдәге мәхәббәт, кешелекле мөнәсәбәтләр, җылы атмосфера – балага һава кебек үк кирәк нәрсәләр. *(“Тигез гомер итегез” китабыннан*).

1. Кайсы җөмләдә ирен гармониясенә буйсынган сүз юк? (В каком предложении не имеется слово с губной гармонией?)

а) 4; ә) 3; б) 2; в) 1.

2. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүз кайсы җөмләдә бар? (В каком предложении имеется слово с губной ассимиляцией?)

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

3. Басымы сүз ахырына төшмәгән сүзләрне билгеләгез. (В каких словах ударение не на последнем слоге?)

а) гомеренең, сабый; ә) гаилә, үсешендә; б) тиешенчә, искиткеч; в) сыйфатлары, мөнәсәбәтнең.

4. Саңгырау тартыклар гына булган сүзләрне күрсәтегез. (Определите слова, имеющие только глухие согласные.)

а) психологик, тәрбиясе; ә) шәхси, кешесе; б) мәктәпкә, башлый; в) дөрес җавап бирелмәгән.

5. Ике аваз кушылмасын белдергән хәрефләр иң күп кулланылган җөмләне билгеләгез. (В каком предложении больше всего встречаются буквы, состоящие из двух звуков?)

а) 4; ә) 5; б) 6; в) 7.

6. Үзара синоним мәгънәсендәге аергыч булган сүзләр кайсы җөмләдә бар? (В каком предложении имеются определения со значением синонима?)

а) 1; ә) 2; б) 3; в) 4.

7. Күчерелмә мәгънәдә кулланылган сүз булган рәтне билгеләгез. (Найдите слово с переносным значением.)

а) үсемлекнең үсүе; ә) нуры кирәк; б) мәхәббәте яктысы; в) әти-әни мәхәббәте.

8. “Бик кирәкле, бик әһәмиятле” мәгънәсен белдергән фразеологизм кайсы җөмләдә бар? (В каком предложении имеется фразеологизм со значением “очень важно, значимо”?)

а) 7; ә) 8; б) 9; в) 10.

9.Тамыр+ясагыч кушымча+модальлек кушымчасы+модальлек кушымчасы+бәйләгеч кушымча калыбына туры килгән сүз кайсы җөмләдә кулланылган? (В каком предложении имеется слово с указанными морфемами – значимыми частями?)

а) 7; ә) 6; б) 9; в) 8.

10. Тамыр сүзләрдән генә төзелгән җөмләнең номерын күрсәтегез. (Определите номер предложения, в котором имеются только корневые слова.)

а) 6; ә) 1; б) 7; в) 2

11. Кайсы җөмләдә бер төрле ысул белән ясалган сүзләр бар? (В каком предложении имеются слова, образованные одинаковым способом?)

а) 5; ә) 4; б) 10; в) 9.

12. Кайсы җөмләдә ике асыл сыйфат, бер нисби сыйфат кулланылган? (В каком предложении имеются два качественных прилагательных, одно относительное прилагательное?)

а) 10; ә) 9; б) 8; в) дөрес җавап бирелмәгән.

13. 5 алмашлык булган җөмләнең номерын языгыз. (Напишите номер предложения, в котором имеются 5 местоимений.)

а) 7; ә) 8; б) 6; в) 5.

14. Кереш сүз булган җөмләне билгеләгез. (Определите предложение с вводным словом.)

а) 5; ә) 4; б) 3; в) 2.

15. Йөкләтү юнәлешендәге ике фигыль кайсы җөмләдә? (В каком предложении имеются два глагола в форме понудительного залога?)

а) 6; ә) 7; б) 10; в) 9.

16. 4 нче җөмләнең дөрес билгеләмәсен табыгыз. (Найдите правильное определение 4 предложения.)

а) аерымланган сәбәп хәлләре булган гади җөмлә; ә) синтетик иярчен рәвеш җөмләле кушма җөмлә; б) тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә; в) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

17. Кайсы җөмләдә ике бәйлек бар? (В каком предложении имеются два послелога?)

а) 3; ә) 4; б) 5; в) 6.

18. Кайсы җөмләдә гомумиләштерүче сүз булып килгән билгеләү алмашлыгы бар? (В каком предложении имеется определительное местоимение в роли обобщающего слова?)

а) 5; ә) 6; б) 7; в) дөрес җавап бирелмәгән.

19. 8 нче җөмләдәге аергычы да, аерылмышы да исем булган сүзтезмәләрнең санын күрсәтегез. (Определите количество словосочетаний, в которых главное и зависимое слово выражены именами существительными.)

а) 2; ә) 3; б) 4; в) 5.

20. Татар телендә сызык куюның 5 очрагын санагыз. Текстта шуларга мисал булса, шул җөмләнең номерын языгыз, булмаганына үз мисалыгызны язып куегыз (5 балл). (Перечислите 5 случаев постановки запятых в татарском языке. Если в тексте есть примеры, укажите номер предложения, если нет – напишите свои предложения).

VI. Нокталар урынына тиешле сүзләр языгыз. – Вставьте вместо точек нужные слова. **(10 баллов)**

1. [а], [ә] - ... күтәрелешле сузык авазлар.
2. [о], [ө], [у], [ү] - ... сузык авазлар.
3. Сингармонизм законына ... һәм ... сүзләр буйсынмый.
4. Сүзләр ... һәм ... мәгънәдә кулланыла.
5. ... ике яки берничә сүздән тора, күчерелмә мәгънәне белдерә һәм бер җөмлә кисәге дип карала.
6. ... предметның кайсы затка караганлыгын белдерә.
7. ... сүзләрне бәйли һәм аларны җөмлә кисәкләре итеп формалаштыра.
8. Кушымчалар, бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр, янәшә тору ярдәмендә ... иярчен җөмләләр баш җөмләгә бәйләнә.
9. Сүзнең ... аны ясауда катнашкан мәгънәле кисәкләр керә.
10. Сүзләр һәм җөмләләр арасында ... һәм ... бәйләнеш булырга мөмкин.

VII. Биремнәрне үтәгез. – Выполните задания. **(11 баллов)**

*Әгәр йөрәгеңдә яшәү дәрте сүнмәсә шомлы караңгы төннәрдә дә күңелеңә куркаклык ояламаса яңа көн туасына ышанычың бетмәсә димәк син яшисең яшәячәксең. (Ф.Яруллин)*

1.Тыныш билгеләрен куеп, аңлатыгыз (поставьте и объясните знаки препинания). (3 балл)

2. Схемасын сызып, төрен языгыз (определите тип предложения, начертите схему). (2 балл)

3. *Сүнмәсә* сүзенә фонетик анализ ясагыз. (1 балл)

4. *Көн* сүзенә лексик анализ ясагыз. (1 балл)

5. *Яшисең* сүзенең төзелешен, ясалышын аңлатма биреп (тамгалар белән генә түгел) тикшерегез. (1 балл)

6. *Йөрәгеңдә, туасына, дә* сүзләренә морфологик анализ ясагыз. (3 балл)

VIII. Җөмлә кисәкләренең астына сызыгыз; гади җөмләгә характеристика бирегез. – Подчеркните члены предложения, дайте полную характеристику простому предложению. **(4 балла)**

*Аның бер уку белән күңелдән ятлана торган ачык яңгырашлы, ямьле ишетелешле һәм эчке музыкага бай, төгәл рифмалы шигырьләрен; тыңлаучыны үзенә җәлеп итүчән һәм тулы бер фикерне җыйнак кына сурәтләндергән хикәяләрен кем генә белми. (Җ.Тәрҗеманов)*

**Ответы**
**межрегиональной предметной олимпиады Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**2011-2012 учебный год**

**11 нче класс**

I. За перевод текста на татарский язык – **5 баллов**, за разгадку – **3 балла**, продолжение сказки – **2 балла**, всего **10 баллов**.

Разгадка: первую часть заработка тратит на питание, вторую часть – на воспитание детей, третью – на содержание престарелых родителей, четвертую – на угощение гостей.

II. За каждый один правильный ответ 25 тестов **по 1 баллу**, всего **25 баллов**.
**Ответы представлены в левом столбике таблицы № 1.**

**Таблица №1**

| **Ответы тестов** | **Ответы тестов по тексту** “Что дает семья ребенку?” |
|---|---|
| 1- в | 1-в |
| 2- ә | 2-ә |
| 3- а | 3-б |
| 4- ә | 4-ә |
| 5- ә | 5-а |
| 6- а | 6-ә |
| 7- ә | 7-б |
| 8- б | 8-в |
| 9- ә | 9-б |
| 10-ә | 10-ә |
| 11-а | 11-б |
| 12-б | 12-а |
| 13-а | 13-ә |
| 14-в | 14-в |
| 15-ә | 15-в |
| 16-б | 16-ә |
| 17-б | 17-ә |
| 18-а | 18-в |
| 19-б | 19-б |
| 20-б | |
| 21-в | |
| 22-а | |
| 23-ә | |
| 24-б | |
| 25-а | |

III. За значение каждого фразеологизма **1 балл**, всего **10 баллов**.

Убегать, недружелюбие, отругать, невнимательность, похваливать, переживать, смеяться, бездельничать, знать назубок, острый на язык.

IV. За исправление речевой ошибки из каждого предложения по **1 баллу**, всего **6 баллов**.

V. После текста “Что дает семья ребенку?” представлены 19 тестов, за каждый один правильный ответ которых **по 1 баллу**, всего **19 баллов**. (**Ответы представлены в правом столбике таблицы № 1.)**

20. За перечисление или представление из текста предложений на каждый случай постановки тире в татарском языке по **1 баллу**, всего **5 баллов.**

1. После однородных членов перед обобщающим словом: 8-е предложение.

2. Между подлежащим сказуемым, выраженными именами существительными: 3-е, 5-е предложения.

3. В бессоюзном сложносочиненном предложении с противительным значением: Кояш чыкты – көн җылынмады. (Взошло солнце – не потеплело.)

4. После уточняемого слова, выраженного существительным, и уточняемыми словами, в составе которых имеются имена существительные: Әлфия – дәү әнисенең яраткан оныгы – 5 нче сыйныфка күчте. (Альфия – любимая внучка бабушки – першела в 5 класс.)

5. После прямой речи перед авторскими словами: “И туган тел, и матур тел!” –дип язган Габдулла Тукай. (О родной язык, красивый язык!” – писал Габдулла Тукай.)

VI. В каждом из десяти предложениях надо вписать слова, всего **10 баллов**.

1) нижний; 2) огубленные; 3) заимствованные, сложные; 4) прямое, переносное; 5) фразеологизмы; 6) притяжательность; 7) падежи; 8) синтетический; 9) основа; 10) сочинительная, подчинительная.

VII. 1)Әгәр йөрәгеңдә яшәү дәрте сүнмәсә, 2)шомлы караңгы төннәрдә дә күңелеңә куркаклык ояламаса, 3)яңа көн туасына 4)ышанычың бетмәсә, 5)димәк, син яшисең, яшәячәксең. - 1)Если не погаснет в твоей душе искорки жизни, 2)в темные ночи не вкрадется в сердце трусость, 3)не исчезнет вера в то, 4)что настанет новый день, 5)значит, ты живешь, будешь жить. (Фанис Яруллин)

1) первые две запятые поставлены между предложениями с сочинительной связью, третья и четвертая – у вводного слова, пятая – между однородными сказуемыми; **(3 балла)**

2)




Это многочленное сложноподчиненное предложение со смешанным подчинением. **(2 балла)**;

3) Фонетический анализ слова *сүнмәсә* **(1 балл).**

Сүнмәсә [с`үм-мә-сә].

В слове 3 слога (1-ый – закрытый, 2-й и 3-й – открытые, 1-ый – ударный).

7 букв (эс, ү, эм, эм, ә, эс, ә), 7 звуков [с`үммәсә].

Гласные [ү], [ә]: [ү] – огубленный, переднего ряда, верхнего подъема; [ә] – неогубленный, переднего ряда, нижнего подъема; наблюдается сингармонизм – небная гармония.

Согласные [с], [м]: [с] – глухой согласный, звонкая пара [з], переднеязычный зубной, щелевой; [м] – губно-губной, сонорный, носовой; наблюдается губная ассимиляция.

Отличается произношение и правописание слова ввиду присутствия губной ассимиляции.

4) Лексический анализ слова *көн.* **(1 балл)**

Употреблено в прямом значении.

Имеется антоним – ночь.

По происхождению общетюркское слово.

По сфере употребления общеупотребительное слово.

Активно употребляется в речи.

Употребляется в составе фразеологизмов: *көнне төнгә ялгап эшләү – трудиться день и ночь.*

5) Морфемный анализ слова *яшисең.* **(1 балл)**

*Яшь* – корень слова;

-*(ә)* –словообразовательный аффикс; имя сущ. → глагол;

-*и* – афф., выражающий отнош., модальности, настоящего времени;

-*сең* – афф., выражающий отнош., связывающий, II лица, ед. числа;

*Яш(ә)* – производная основа.

6) Морфологический анализ слов *йөрәгеңдә, туасына, дә* **(3 балла)**:

*Йөрәгеңдә* – имя существ., конкретное, нарицательное, ед. числа, притяжательность II лица ед. числа, местно-врем. падежа, обстоятельство места, производное сущ.

*Туасына* – причастие, основной залог, в форме утверждения, будущего времени, наблюдается субстантивация – в направительном падеже, сказуемое в придаточном дополнительном предложении синтетического типа.

*Дә* – усилительная частица.

VIII. Это – простое, утвердительное, двусоставное, полное, осложненное с однородными определениями и дополнениями предложение, наблюдается инверсия между дополнением и главными словами (*шигырьләрен, хикәяләрен кем генә белми).*

*Кем* - подлежащее*; белми* – сказуемое.

*Уку белән, хикәяләрен, шигырьләрен, үзенә, фикерне* – дополнения;

*Аның, ятлана торган, яңгырашлы, ишетелешеле, эчке, бай,өгап, рифмалы, җәлеп итүчән, тулы, сурәтләндергән* – определения;

*Бер, күңелдән, ачык, ямьле, җыйнак* – обстоятельства образа действия. **(4 балла)**